КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 6 декабрь г.Казань № 1289

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 26 август, 904 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә стратегик һәм махсус авиация техникасы (самолетлар) җитештерүче оборона-сәнәгать комплексы оешмаларына, аларны җитештерүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында, субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы территориясендә стратегик һәм махсус авиация техникасы (самолетлар) җитештерүче оборона-сәнәгать комплексы оешмаларына, аларны җитештерүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында, субсидияләр бирү тәртибен раслау турында" 2022 ел, 26 август, 904 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә стратегик һәм махсус авиация техникасы (самолетлар) җитештерүче оборона-сәнәгать комплексы оешмаларына, аларны җитештерүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында, субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет

системасының бердәм порталындагы «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

5 пунктның өченче абзацында «30 календарь көннән иртәрәк» сүзләрен «10 календарь көннән иртәрәк» сүзләренә алмаштырырга;

17 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);».

2. Бу карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин